| | |
|---|---|
| ГЛАВА<br>МУРАЛИНСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>КАЙБИЦКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН<br>РЕСПУБЛИКАСЫ<br>КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ<br>МӨРӘЛЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>БАШЛЫГЫ |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ                                        КАРАР

25 ноябрь, 2024 ел                    Мөрәле ав.                    № 5

Гражданнарның үзара салым акчаларын
кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча
Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль
районы Мөрәле авыл җирлегенең Мөрәле авылында
гражданнар җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Мөрәле авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә КАРАР КЫЛАМ:

1. 2024 елның 5 декабренә 14 сәг 00 минутка Мөрәле ав., Яшьләр ур, 1 нче йорт адресы буенча урнашкан мәктәп бинасында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Мөрәле авыл җирлегенең Мөрәле торак пунктында үзара салым алып бару мәсьләләре буенча гражданнар җыенының ***беренче этабын*** билгеләргә.
2. 2024 елның 6 декабренә 11 сәг 00 минутка Мөрәле ав., Үзәк ур., 70А йорт адресы буенча урнашкан мәчет бинасында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Мөрәле авыл җирлегенең Мөрәле торак пунктында үзара салым алып бару мәсьләләре буенча гражданнар җыенының ***икенче этабын*** билгеләргә.
3. 2024 елның 6 декабренә 14 сәг 00 минутка Мөрәле ав., Үзәк ур., 45нче йорт адресы буенча урнашкан мәдәният йорты бинасында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Мөрәле авыл җирлегенең Мөрәле торак пунктында үзара салым алып бару мәсьләләре буенча гражданнар җыенының ***өченче этабын*** билгеләргә.
4. 2024 елның 7 декабренә 10 сәг 00 минутка Мөрәле ав., Гагарин ур., 14а нче йорт адресы буенча урнашкан “Ак каен” кибете янында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Мөрәле авыл җирлегенең Мөрәле торак пунктында үзара салым алып бару мәсьләләре буенча гражданнар җыенының ***дуртенче этабын*** билгеләргә
5. 2024 елның 9 декабренә 10 сәг 00 минутка Мөрәле ав., Карла Маркса ур., 69 нчы йорт янында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Мөрәле

авыл җирлегенең Мөрәле торак пунктында үзара салым алып бару мәсьәләре буенча гражданнар җыенының ***бишенче этабын*** билгеләргә

6. 2024 елның 9 декабренә 14 сәг 00 минутка Мөрәле ав., Карла Маркса ур., 34 нчы йорт янында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Мөрәле авыл җирлегенең Мөрәле торак пунктында үзара салым алып бару мәсьәләре буенча гражданнар җыенының ***алтынчы этабын*** билгеләргә
7. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2025 елда Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының яшәү урыны буенча Мөрәле авыл җирлеге территориясендә теркәлгән һәм даими яшәүче балигъ булган һәр яшәүчедән 700 (җиде йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме:

- су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алу, аны чистарту, су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су башняларын, скважиналарны һәм башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;
- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;

Экономия барлыкка килгән очракта, аерым мәсьәләләр буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Мөрәле авыл җирлеге Башкарма комитетына җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен акча җибәрергә рөхсәт итәргә.»

« РИЗА» «КАРШЫ»

8. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Мөрәле авыл җирлеге башлыгының» Кайбыч муниципаль районы Мөрәле авыл җирлегенең Мөрәле авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында " 2024 елның 13 ноябрендәге 3 номерлы карарын гамәлдән чыккан дип санарга.

9.Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Мөрәле авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка таратырга һәм «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru), һәм Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Мөрәле авыл җирлегенең рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://muralin-kaybici.tatarstan.ru./ урнаштырырга.

10. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Республикасы Кайбыч муниципаль районының
Мөрәле авыл җирлеге Башлыгы Р.Р.Зиннатуллин